КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1093

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче, 2016 ел, 15 февраль, 73 нче, 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган

мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 17 һәм 18 пунктларны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «17. | Эшмәкәрләр берләшмәсенең Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге белән канәгать булуы, процент | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | ел саен | Аналитик мәгълүматлар узган ел дәрәҗәсендә яки уңай динамика |
| 18. | Хезмәткә яраклы яшьтәге инвалидларның гомуми санында эшләүче инвалидлар саны, процент | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | квартал саен (арта баручы нәтиҗә белән) | V = A / B × 100, монда:<br>A – муниципаль районда (шәһәр округында) хезмәткә яраклы яшьтәге эшләүче инвалидлар саны, кеше<br><br>B – муниципаль районда (шәһәр округында) яшәүче хезмәткә яраклы инвалидларның гомуми саны, кеше». |

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин